# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**3 ноябрь 2023 ел** **№2**

2024 елда Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы Уразай
авыл җирлеге Уразай торак пунктында
гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Уразай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1.2024 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгәннәрнен гаилә эгъзаларыннан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр очен 150 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Уразай авылының тышкы урам яктырту челтәрләрен ремонтлау( урам яктырту өчен электр товарлары сатып алу, урам яктырту яктырткычларын алыштыру һәм урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтү) ;
-Уразай авылында 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар хөрмәтенә һәйкәл төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;
- Уразай авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту(тракторчыга механизацияләнгән кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү)..

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 кон эчендә, Уразай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы ____________ А.М.Шэрифуллина
Уразай авыл җирлеге башлыгы (имза) (имза расшифровкасы)